**«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы
10 нчы гимназия» гомуми белем бирү учреждениесе**

# Эзләнү эше

# **Тема:** Якташыбыз-легендар җырчы Усман Әлмиев иҗаты

Автор: Шакирова Әдилә,9 А сыйныфы

Укытучы: Җамалиева Л.И

Яшел Үзән, 2020

# ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ........................................................................................................ 3-4

I БҮЛЕК.Усман Әлмиевның тормыш юлы..................................................5-6

II БҮЛЕК.Усман Әлмиевның опера һәм эстрада өлкәсендәге эшчәнлеге...7-11

ЙОМГАК..........................................................................................................12-13

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ........................................................................ 14

# Кереш

Яшел Үзән районы – татар халкына бик күп талантлы ул һәм кызлар бүләк иткән төбәк. Бу яктан атаклы язучылар да, шагыйрьләр дә, төрле фән өлкәләрендә эшләгән абруйлы галимнәр дә чыккан. Каюм Насыйри, Афзал Шамов, Идрис Туктар, Азат Вергазов, Шәриф Сайкин, Гомәр Саттаров, Йосыф Гыйззәтуллин, Наиль Әмиров, Нәзим Ханҗафаров, Резидә Төхвәтуллина, Константин Васильев кебек атаклы кешеләрнең исемнәре генә дә ни тора!

Татарстанның халык артисты, татар операсына нигез салучыларның берсе, легендар җырчы Усман Әлмиев та Яшел Үзән төбәгеннән.

Безнең фәнни эшебез – "Якташыбыз-легендар җырчы Усман Әлмиев иҗаты" дип атала.

**Теманың актуальлеге:** Әдәбият укытуга бүленгән сәгатьләр саны чикле булу сәбәпле, сыйныфтан тыш уку дәресләрендә генә үзебезнең җирлектән чыккан күренекле шәхесләрнең иҗат юлын өйрәнергә мөмкинлек юк. Шул ук вакытта якташларыбыз иҗаты аз өйрәнелгән өлкә булып та санала. Минемчә, без, укучылар, әдәбият һәм сәнгать күгендә якты йолдыз булып янучы якташ әдипләребезнең тормыш һәм иҗат юлы турында хәбәрдар булырга тиешбез.

***Максатыбыз*** – Якташыбыз Усман Әлмиев иҗатына күзәтү ясау.

Максаттан чыгып без үз алдыбызга түбәндәге ***бурычлар*****ны** куйдык:

-Усман Әлмиевның тормыш юлы белән танышу;

- җырчының опера өлкәсендәге эшчәнлегенә күзәтү;
- халык җырларын популярлаштыруга, татар эстрадасын үстерүгә керткән хезмәтләре турында мәгълүмат туплау.

Фәнни-тикшеренү эшенең төп ***объекты*** –Усман Әлмиев иҗаты.

Әлеге эшне башкарганда түбәндәге ***метод-алымнар*** кулланылды: күзәтү, гомумиләштерү, тикшеренү, эзләнү, анализлау, нәтиҗә ясау.

***Фәнни эшнең структурасы***. Фәнни эш керештән, төп өлешнең ике бүлегеннән, йомгаклау һәм кулланган әдәбият исемлегеннән тора.

Фәнни-тикшеренү эшен башкарганда Усман Әлмиевның “Еллар һәм җырлар” китабы, татар энциклопедик сүзлеге, газета-журнал материаллары файдаланылды.

## I БҮЛЕК. **Усман Әлмиевның тормыш юлы**

Усман Әлмиев 1915 нче елда Яшел Үзән районы Акъегет авылында дөньяга килә. Революциядән соңгы ачлык елларында, әти-әнисе вафат булгач, биш яшеннән балалар йортында үсә ул. Шунда ук сигез класс белем алгач, Алабуга авыл хуҗалыгы техникумына укырга җибәрелә. Техникумда үзешчән сәнгатьтә катнаша башлый. Егеттә артистлык сәләте ачыла. Мондыйлар тагын була. Киләчәктә татар сәхнәсенең йөзек кашына әвереләчәк Усман, Динә Сираҗиева һәм Зифа Басыйрова беренче курсны тәмамлау белән Казанга, театр техникумына китәләр. Ул актерлык осталыгы дәресләрен Г. Камал исемендәге Татар драма театрында ала башлый. Бу чорда театрда музыкаль бүлекне танылган татар композиторы  Салих Сәйдәшев җитәкли торган була. Драматик актерлар - Зәйни Солтанов, Хөсәен Уразиков, Фатыйма Ильская, җырчылар-Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкаяларны сокланып сәхнәдән күзәтә. Көндезләрен аларның репетицияләрендә була. Шул ук вакытта Усман музыка техникумында танылган педагог Екатерина Ковельковадан вокал дәресләре ала.

Бервакыт дәрес вакытында класска таныш түгел кеше килеп керә һәм «Сездән җырчы чыгачак, консерваториядә белем алачаксыз, әзерләнегез », - дип чыгып китә. Бу Мәскәү консерваториясенең профессоры Н. Г. Райский була.

Усман Әлмиев Мәскәү консерваториясенең опера студиясенә килгәндә, класслар билгеләнеп, мөгалим-остазлар төрле укытучыларга бүленеп беткән була. Шулай да, профессор Софья Друзякина татар егетен тыңлап карарга ризалаша һәм аны үз классына ала. Софья ханым кулыннан килгәнчә егеткә ярдәм итә, аны улы кебек күрә.

1938-1968 елларда У. Әлмиев М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры һәм Г.Тукай исемендәге дәүләт филармониясе солисты булып хезмәт куя. Тамашачылар аны «Алтынчәч», «Шагыйрь», «Жәлил», «Галиябану», «Самат», «Башмагым» һ.б. спектакльләрендәге образлары аша бүген дә сагынып искә ала. Моннан тыш Усман ага татар халык җырларын популярлаштыруда да зур көч куя. «Урман кызы» (Җәүдәт Фәйзи), «Соңгы көрәшкә»(Фәрит Яруллин), «Кил, чибәрем» (Рөстәм Яхин) әсәрләрен дә беренче булып ул башкара. 1945 елда

ТАССРның атказанган, ә 1957 елда ТАССРның халык артисты исеменә лаек була. 30 елдан артык Татарстан театр әһелләре берлегендә эшли, 20 елын аңа җитәкчелек итә.

2011 нче елның 15 нче апрелендә Казанда үлә.

## II БҮЛЕК. **Усман Әлмиевнын опера һәм эстрада өлкәсендәге эшчәнлеге**

Ул татар опера сәнгатен үстерүгә гаять зур көч куйган шәхесләрнең берсе.Усман Әлмиев опера сәхнәсендә әйдәп баручы партияләрне башкара. «Алтынчәч», «Шагыйрь», «Җәлил», «Галиябану», «Самат», «Башмагым» һ.б. спектакльләрдә кабатланмас образлар тудыра.

1939 нчы елда “Качкын “операсы белән Татар дәүләт опера театры ачыла. Репертуарда Ш.Гуноның “Фауст”ы бара. Аннан соң Мәскәүдә укып кайткан Гай Таһиров П.Гертельнең “Тщетная предосторожность” балетын Мәскәү укытучылары белән берлектә әзерли.1939 нчы елның 9 сентябрендә Качалов исемендәге театрда бу балетны тамашачыга күрсәтәләр.Бу балетта Усман Әлмиев Нотариус ролен башкара.

Усман Әлмиевка үз гомерендә бик күп җылы сүзләр дә, алкышлар да ишетергә туры килә. Кем дип кенә атмаганнар аны. “Еллар һәм җырлар” дигән китабында “Урамда барганда таныйлар, “Башмагым!” дип кычкыралар иде,”-дип яза. Җәүдәт Фәйзинең “Башмагым” әсәре Әлмиевны Казанда таныта да инде. Бу әсәр сәхнәгә 1942 елда куела. Халык аны бик яратып каршы алган, билетлар алдан ук, әллә кайчан сатылып беткән. Көнгә өчәр спектакль куелган. “Аның икесен - кич, берсен иртән уйнадым. Шуннан соң бик популяр артист булып киттем”,- дип яза Усман ага. Операның язылу тарихы белән дә танышып китик. Усман Әлмиев 1941нче елда Җәүдәт Фәйзигә "Башмагым" опереттасын язарга киңәш итә. Аның пьесасын Таҗи Гыйззәт түгел, Уфада яшәүче Хәбибулла Ибраһимов иҗат итә. Таҗи Гыйззәт икенче пәрдәне яза, Себер баен кертә дә, эшкәртеп, бер дигән оперетта әзерләп бирә. Фәхри Насретдинов белән Усман Әлмиев -Галимҗанны, Сара Садыйкова белән Галия Кайбицкая - Сәрвәрне җырлыйлар. 1942 елның мартында премьерада Галия Кайбицкая белән җырлый. Бу музыкаль комедиядә Галимҗан роле-Усман Әлмиевның иң уңышлы рольләреннән берсе була. Артист гаҗәеп мөлаем, тапкыр,терекөмеш кебек җитез егет образын иҗат итә.Галимҗан ролен ул үзе дә бик ярата торган булган. Аның бер концерты да Галимҗан җырын җырламыйча

узмаган.”Башмагым” да ничә йөз мәртәбә уйнаганмындыр-хәтерләмим, әмма һәр спектакль сәхнәгә тәүге чыгу сыман бик дулкынландыра торган иде. Бу героемны бик яраттым, бик хөрмәт иттем,”-дип сөйли торган булган актер.

Опера җырчысы буларак, татарның бөтен опералларында  җырлап чыга Усман Әлмиев.

Сугышка кадәр Казанда “Качкын”, “Галиябану”, “Ирек”,  “Фауст”, “Алтынчәч” опералары тамашачыга күрсәтелә.1944 нче елда “Шагыйрь” исемле опера куела. Ул Муса Җәлил тормышыннан язылган була. Операда Җәлилне немецлар баганага бәйләп яндыралар . Ул Нәҗип Җиһановның беренче операсы. Соңыннан ул аны “Җәлил” итеп эшли. ”Мин Муса Җәлилне башта Уралов итеп җырладым”,- дип искә ала Усман Әлмиев. Алар Җәлил белән яхшы таныш булганнар. Казанда да, Мәскәүдә укыганда да аралашканнар.

Усман Әлмиев татар композиторларының операларында төп партияләрне башкара: Җик һәм Урмай, Хәйдәр, Нияз Уралов, Канзафаров («Алтынчәч», «Намус», «Шагыйрь», «Җәлил», Н. Җиһанов), Бәдри («Галиябану», М. Мозаффаров), Самат (шул исем. опера, Х. Вәлиуллин). Популяр музыкаль комедияләрдә төп рольләрне башкара: Әскәр («Аршин мал алан», Г. Гаҗибәков), Галимҗан («Башмагым», Җ. Фәйзи). Артистның уңышы сәхнәдә үзен иркен тотуы, тавышының тәэсирле булуы, образларны ышандырырлык итеп тудыруы һәм ачып бирүе белән бәйле. Аның башкару стиленә тирәнтен индивидуальләштерү, характерларны төгәл сурәтләү, образларны оригиналь чагылдыру хас.

Гозәер Хаджибәковның “Аршин мал алан” музыкаль комедиясе 1947 нче елда сәхнәгә куела.Ул спектакльдә Усман Әлмиев  Әскәр ролен башкара.Башта әсәр кинотеатрларда рус телендә зур уңыш белән бара. Опера театры татар телендә куйгач та, тамашачы театрга бик теләп йөри. Спектакль азәрбайҗан тормышын ачарлык итеп, бөтен шартларын җиренә җиткереп эшләнә. Музыкасы халыкчан, тыңлаучыларга якын, матур мелодияләр була.Әсәр бик җылы, җиңел язылганга, тамашачы күңеленә үтеп керә.

Усман Әлмиев совет композиторлары операларында да җырлаган. Д.Кабалевскийның «Семья Тараса» спектаклендә ул Андрей ролен башкарган. Дж.Вердиның «Трубадур»ында, Р.Корсаковның «Кыр казы» операларында да ул уңышлы чыгыш ясаган. 1953 нче елда Н.Римский-Корсаковның «Снегурочка» операсы куела. Усман Әлмиев анда Бируччны җырлый. Зур роль булмаса да, җырлаганда һәрвакыт алкышларга күмәләр аны.

Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына “Алтынчәч” һәм “Самат”опералары әзерләнә. “Самат” операсында Усман Әлмиев Самат партиясен башкара.Бу образның эчке кичерешләрен бик төгәл ачуы,нечкә хисләрне җыр аша тамашачыга җиткерүе белән ул зур уңыш казана.

1990-1991 нче елларда Татар опера театры С.Сәйдәшевның “Наемщик” музыкаль драмасын куя.Бу спектакльдә Усман Әлмиев Иманкол мулла образын башкара.Ә 1949-1950 нче елларда ул Батырҗан ролен уйнаган була.

Усман Әлмиевнең тавышы тигез, матур тембрлы, бик музыкаль, сыгылмалы була. Бу җырчы киң диапазонга ия булганга, операларда һәм баритон, һәм тенор партияләрен башкара алган. Артист бервакытта да, кечкенә партияләрдә сәхнәгә чыксам, дәрәҗәм төшәр, дип курыкмаган. Кинәт авырып киткән артистны, роле зурмы, кечкенәме булуына карамыйча, бик теләп алыштыра торган булган. Гомумән алганда, оста җырлаучы һәм драматик актер сәләтенә ия Усман Әлмиев күп кенә опера башкаручыларыннан бер баскыч югарырак торган.

Усман Әлмиев концерт эстрадасында да үзен зур оста итеп таныта

Усман ага үзе дөньяга “Сарман” белән чыктым, ди. “Бездә “Сарман”ны “Әрә көе” дип йөриләр иде. 1938 елда Мәскәүдә консерваториядә укыганда Заһид Хәбибуллиннан эшкәрттереп, гел шуны башкардым. Зачетта да народные песни урынына “Сарман” ны җырладым. Кайткач радиодан да гел җырлап тордым. Мин алып чыккан җырлар бик күп. Сугышка озатканда, кайтканда “Арча” көен җырлый иделәр. Мин аңа текст язып куштым да, “Арча көе” шулай барлыкка килде”, ди Усман Әлмиев. Мин башкармаган халык җыры юк ул, ди.

Эстрада концертларында татар халык җырларын тирән хис белән башкарып, тамашачы күңелен яулый. Җырчы репертуары татар композиторлары һәм СССР халыклары җырларыннан тора. Ул - Җ. Фәйзинең «Урман кызы», Ф. Яруллинның «Соңгы көрәшкә», Р. Яхинның «Кил, чибәрем» җырларын беренче башкаручы. «Татарстан» ДТРК фондында аның башкаруында 90 нан артык җыр һәм арияләр язмалары саклана.

Татар җырчыларыннан беренче буларак, ул эстрада сәхнәсенә театральлекне алып килгән. Аудитория белән якын итеп, үз итеп сөйләшкән.Тамашачылар игътибарын җыр белән генә түгел, сүз, хәрәкәт, күз карашы, мимика белән җәлеп итә белгән. Боларның барысын да бер максатка-җырны кеше күңеленә үтемлерәк итү өчен файдаланган.Усман Әлмиевның җыр башкаруы, спектакль күренеше кебек, бик җанлы, образлы кабул ителгән. Җ.Фәйзи җырларының, “Партизанка Гөлсара”, “Атым, чайка башыңны”, “Канга-кан, үлемгә-үлем!”һ.б. күп кенә җырларының геройлары әйтерсең лә сәхнәдә терелә торган булган. Сара Садыйкованың Сибгат Хәким сүзләренә язылган “Минем еллар-минем байлыгым” җыры Усман Әлмиевның үз язмышы турында кебек. Рөстәм Яхинның Гарифҗан Мөхәммәтшин сүзләренә иҗат иткән “Керим әле урманнарга”, Хөснул Вәлиуллинның Әхмәт Ерикәй сүзләренә “Онытырга мөмкин түгел”җырларын да ул бик оста башкарган. Бу җырлар белән җырчы үзенең озак еллар иҗат итеп бай тәҗрибә туплаган , прфессиональлекнең иң югары дәрәҗәсенә җиткән зур шәхес булуын раслый.Усман Әлмиев башкаруында бу җырлар бик табигый яңгырый һәм зур ышандыру көченә ия. Гомумән алганда, җырчыга эчке хисләр белән сирәк җырлана торган әсәрләрне башкару хас.

Усман Әлмиевның татар халык җырларын башкаруындагы осталыгы турында да әйтеп үтми мөмкин түгел.Халык җырлары-аның иҗатының иң зур казанышы. Музыка белгече Нәркиз Мөштәри Усман Әлмиев башкаруындагы халык җырларыннан гына торган дүрт радиотапшыру ясады. Анда җырның кайда, ничек тууы турында бай мәгълүмат та китерелә.

Усман Әлмиев, 80 яшен уздыргач, бала чагында , яшьлек елларында ишеткән, халыкта онытыла барган  борынгы җырларны яздырып, аларга яңа тормыш бүләк итә. Аның халык җырларының гомерен озайту юнәлешендә алып барган эшчәнлеге дә бәяләп бетергесез зур.

**Йомгак**

Һәр төбәкнең танылган шәхесләре була. Безнең Яшел Үзән якларыннан да бик күп талантлы кешеләр чыккан. Шуларның берсе-Татарстанның халык артисты, Бөтенроссия җырчылар конкурсы лауреаты, татар Опера театрына нигез салган солистларыбызның берсе, гаҗәеп бай репертуарлы концерт җырчысы Усман Әлмиев.

Безнең максат якташыбыз Усман Әлмиевның опера өлкәсендәге эшчәнлегенә күзәтү ясау, халык җырларын популярлаштыруга,татар эстрадасын үстерүгә керткән хезмәте белән танышу иде.

Усман Әлмиевның иҗаты белән танышып чыкканнан соң шундый нәтиҗәләргә килдек:

1.Усман Әлмиев-татар опера сәнгатенә нигез салучы, талантлы опера җырчысы. Ул, опера җырчысы буларак, татарның бөтен операларында җырлап чыга .

Усман Әлмиев татар композиторларының операларында төп партияләрне башкара: Җик һәм Урмай, Хәйдәр, Нияз Уралов, Канзафаров («Алтынчәч», «Намус», «Шагыйрь», «Җәлил», Н. Җиһанов), Бәдри («Галиябану», М. Мозаффаров), Самат (шул исем. опера, Х. Вәлиуллин). Популяр музыкаль комедияләрдә төп рольләрне башкара: Әскәр («Аршин мал алан», Г.Гаҗибәков), Галимҗан («Башмагым», Җ. Фәйзи). Артистның уңышы сәхнәдә үзен иркен тотуы, тавышының тәэсирле булуы, образларны ышандырырлык итеп тудыруы һәм ачып бирүе белән бәйле. Шагыйрь Роберт Әхмәтҗан сүзләре белән әйтсәк:

Син салыштың иң беренче милли
Операның нигез ташларын...
Маэстро!Олы иҗат юлың
Син Җәлилләр белән башладың!
Нигезләштең Татар операсын,
Милли сәнгаткә бу-таң иде!
Йолдыз булып күккә күтәрелгәч,

Халкың сине үзе таныды!

Бу-тарихта үзе дан инде...

2.Усман Әлмиев -эстрада өлкәсендә танылган җырчы, халык җырларын гаҗәеп оста башкаручы артист.

Татар җырчыларыннан беренче буларак, ул эстрада сәхнәсенә театральлекне алып килгән. Җырны кеше күңеленә үтемлерәк итү өчен тырышкан.Усман Әлмиевның җыр башкаруы, спектакль күренеше кебек, бик җанлы, образлы кабул ителгән.

“Сарман”, “Арча”, “Керим әле урманнарга”,”Кил, чибәрем”, “ Урман кызы” һ.б.җырларны гаҗәеп оста башкарган, тамашачыларның мәхәббәтен яулаган.Ул, беренчеләрдән булып, Бөтенсоюз конкурсларында катнашып, дипломнар һәм лауреат исемнәре алган.

Шундый талантлы якташым белән чиксез горурланам, аның бай, сокландыргыч хезмәтенә баш иям.

Усман Әлмиевның туган авылы-Акъегеттәге урта мәктәп аның исемен йөртә. Мәктәптә Усман Әлмиев музее эшләп килә. Без шундый олы шәхесләрне онытырга тиеш түгел. Аларны киләчәк буыннар да белсен, аларның иҗатын өйрәнсен иде.

## Кулланылган әдәбият


1.Алмеев.У.Г.Еллар һәм җырлар.-Казан:Татар.кит.нәшр., 2007

2. Искәндәр Сиражи.Усман ага турында. // Татарстан яшьләре.-2004.- 7 нче февраль.

3. Г. Кантор. Усаман Гафиатович Альмеев//Казань-музыка-XX век. Исследовательские очерки.-Казань: Издательский дом «Титул-Казань», 2007.- С.66.

4. Тазиева К.Осень патриарха.//Республика Татарстан.-2005.-№ 87

5. Татарский энциклопедический словарь. — Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1998

6. Хайруллина З. Альмеев Усман Гафиятович//Народные артисты: Очерки.— Казань, 1980. С. 456—459.

7. http://tatarile.org/maglumat/ шәхес/әлмиев-альмеев-усман-гафият-улы